ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15 05 2020 г. № 298

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 декабрендәге 2395 номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждение (бюджет, автоном) җитәкчесе вазыйфасына, шулай ук муниципаль учреждение (бюджет, автоном) җитәкчесе булып эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үзенең иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру һәм Түбән Кама муниципаль районы Советының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 29 апрелендәге 39 номерлы карары белән, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 декабрендәге 2395 номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждение (бюджет, автоном) җитәкчесе вазыйфасына, шулай ук муниципаль учреждение (бюджет, автоном) җитәкчесе булып эшкә керүче зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм үзенең иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктның өченче абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов